**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**14 ноябрь 2021 ел. № 1**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Кызыл Шәрыкъ торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында 2021 елның 14 ноябре,**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 2131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче маддәсе нигезендә 2021елның 14 ноябрендә 10.00 сәгатьтә «2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Кызыл Шәрыкъ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым акчаларын керту һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?» мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре беркетмәсе төзелде:

а) иске агачларны кисү;

б) Кызыл Шәрыкъ торак пункты эчендәге юлларга вак таш сатып алу һәм ремонт ясау.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 58 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -35, бу 60% тәшкил итә

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 35 кеше «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Кызыл Шәрыкъ авыл җирлегендә халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга..

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Кызыл Шәрыкъ торак пункты территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

Экономияләнгән акчаны Шәпше авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга рөхсәт итәргә.

3.Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ Фәрит Мөхәммәтшин «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге сәяси советы утырышын уздырды http://pravo.tatarstan.ru/

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Шәпше авыл җирлеге башлыгы В.А.Беляков